| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| «12» ноябрь 2020 ел | №14 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**51 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацын** «яисә әлеге орган исеменнән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эш итәргә вәкаләтле башка зат» сүзләре белән тулыландырырга.

**10 статьяның 2 абзацы** үз көчен югалткан дип танырга.

**39 статьяның 3 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм закон чыгару (вәкиллекле) органына карау өчен бюджет турында закон (карар) проектын керткәннән соң кабул ителгән Федераль законнар нигезләмәләре, Татарстан Республикасы законнары, авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының муниципаль хокукый актлары агымдагы финанс елында һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Туктар-Урдаласы авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә (leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Ә.Әхмәтова